ГЛАВА
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.04.2021 Әгерҗе шәһәре № 41

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгының
«Социаль хезмәтләр күрсәтүче учреждениеләрнең эш сыйфатын бәяләүнең
бәйсез системасын формалаштыру турында» 2013 елның 27 декабрендәге
128 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Әгерҗе районы прокуратурасының «Социаль хезмәтләр күрсәтүче учреждениеләрнең эш сыйфатын бәяләүнең бәйсез системасын формалаштыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгының 2013 елның 11 мартындагы 02-08-01 номерлы карарына протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында Иҗтимагый совет эшчәнлегенә карата федераль законнар бозуларны бетерү турында Әгерҗе районы прокуратурасының 19.03.2021 № 02-08-02/131 күрсәтмәсе, к а р а р и т ә м:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгы карарларының үз көчен югалтуын танырга:

«Социаль хезмәтләр күрсәтүче учреждениеләрнең эш сыйфатын бәяләүнең бәйсез системасын булдыру турында» 2013 елның 27 декабрендәге 128 номерлы карар;

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгының 2013 елның 27 декабрендәге 128 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иҗтимагый советы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 02 августындагы 87 номерлы карар.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Общий отдел
Гомуми бүлек

**А.Р. ВӘЛИЕВ**